Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 26 нчы июнь
437 нче номерлы карары белән расланган
1 нче кушымта

Түбән Кама муниципаль районында 2018-2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Сәйфетдинов Айдар Габдуллаҗан улы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Нигъмәтҗанов Альфред Галим улы | - | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, җирле үзидарә органнары белән бәйләнеш һәм муниципальара хезмәттәшлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары. |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Салаватов Айрат Ринат улы | - | Ростехнадзор Идел буе идарәсенең Түбән Кама территориаль бүлеге башлыгы (килешенү буенча); |
| Төхватуллин Айрат Сәгыйть улы | - | Ростехнадзор Идел буе идарәсенең Түбән Кама территориаль бүлегенең газ бүлү һәм газ куллану челтәрләренә күзәтчелек буенча дәүләт инспекторы; |
| Вафин Рамил Шәүкәт улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсе каршындагы Түбән Кама территориаль бүлеге челтәрләренә һәм җылылык энергиясенә күзәтчелек буенча дәүләт инспекторы; |
| Вафин Рәдиф Шәүкәт улы | - | Ростехнадзорның Идел буе идарәсенең Түбән Кама территориаль бүлегенең электр энергиясен күзәтү буенча дәүләт инспекторы; |
| Ихсанова Наилә Нариман кызы | - | Түбән Кама зонасы торак инспекциясе башлыгы (килешенү буенча); |
| Слободюк Константин Петрович | - | Түбән Кама муниципаль районы буенча ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсе башлыгы (килешенү буенча); |
| Соловьев Сергей Степанович | - | «Индустриаль Парк-Сервис» «ИК» ҖЧҖ директоры; |
| Хамхоев Артур Магомедович | - | «Җылылык Сервисы» ҖЧҖ директоры; |
| Демьянов Владимир Евгений | - | «Су каналы-КП» ҖЧҖ директоры; |
| Галиев Рифат Габделхәй улы | - | «БРИГ» ҖЧҖ, «Ширәмәт ЖилСтройСервис» ҖЧҖ директоры. |

2. Җылылык энергиясен кулланучылар җылылык белән тәэмин итүче оешмага 4 нче кушымтаның 2, 5, 8 нче пунктларында күрсәтелгән әзерлек таләпләрен үтәү буенча мәгълүмат тапшыралар. Кулланучылар, 4 нче кушымтаның 1, 3, 4, 9, өлешчә 10, 15, 17 пунктларында күрсәтелгән таләпләрнең үтәлеше буенча мәгълүматны комиссия таләбе буенча карауга ТКХ департаментына мөстәкыйль рәвештә тапшыралар.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма кулланучыларның җылылык энергиясен исәпкә алу төеннәрен эксплуатацияләүгә кертүне гамәлгә ашыра, җылылык пунктларының тыгызлыгы һәм ныклыгы өчен җиһазларын сынаганда, теплофикация суы белән җылылык файдалану системаларын гидропневамтик юдырганда катнаша һәм тикшерү объектларын карап чыга.

Җылылык белән тәэмин итүче оешма 2018/2019 еллар ягу чорына әзерлекне тикшерү актын рәсмиләштерә һәм аны ТКХ департаментына комиссия каравына җибәрә.

Атна саен пәнҗешәмбе көннәрендә җылылык белән тәэмин итүче оешма ТКХ департаментына кулланучылар объектларын ягу чорына әзерләү буенча белешмә рәвешендә мәгълүмат бирә.

Комиссия Программаның 2.2 пункты нигезендә әзерлек таләпләрен үтәүне раслаучы документларны карый.

- җылылык, электр, ягулык һәм су белән тәэмин итү оешмаларының, җылылык энергиясен кулланучыларның, ремонт-төзелеш һәм транспорт оешмаларының, шулай ук җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешен исәпкә алып, җылылык белән тәэмин итү системаларында аварияне бетерү тәртибе булу;

- җылылык челтәрләренең гидротехник һәм җылылык сынауларын үткәрү;

- җылылык белән тәэмин итүдә катнашучы җайланмаларга кирәкле техник тикшерү һәм диагностика үткәрүне үз эченә алган ягу чорында эшкә әзерлекнең расланган планын үтәү;

- җылылык челтәрләрен һәм җылылык энергиясе чыганакларын ремонтлауның план графигын үтәү;

- ягулык белән тәэмин итү өзеклекләренә юл куймый торган һәм ягулык запасларының билгеләнгән нормативларын киметмәүче ягулык белән тәэмин итүгә шартнамәләр булу;

12) җылылык энергиясен кулланучылар, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмалары арасында эксплуатацион җаваплылыкны чикләүне билгеләүче документлар булу;

13) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән ягу чорында эшнең ышанычлылыгына йогынты ясый торган билгеләнгән вакытта үтәлмәгән күрсәтмәләрнең булмавы;

14) булган очракта, автоматик көйләгечләрнең эшләве.

Җылылык һәм электр энергиясе җитештерү объектларына карата катнаш эшләп чыгару режимында бары тик электр энергетикасы турындагы закон нигезендә ягу сезонына әзерлек турындагы документның булуы гына тикшерелә.

Аларны үтәмәгәндә, җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык челтәрләре оешмаларына карата, кисәтүләрне бетерү срокларын күрсәтеп, Исемлек кушымтасы белән акт төзелә торган шартларга әлеге 3 нче кушымтаның 1, 7, 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү керә.

